# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**18.10.2024** **№ 1**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 18 октябрендә 09:00 сәг.тә уздырылган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә члennarын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материалы сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, аларны чистарту, су белән тәэмин итү (сантехник һәм чыгым материалларын, тирәнлек насосларын сатып алу, сүүткәргеч челтәрне ремонтлау һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 17 кеше, бу 54,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 17 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гали торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче гражданнардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә членнарын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материалы сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, аларны чистарту, су белән тәэмин итү (сантехник һәм чыгым материалларын, тирәнлек насосларын сатып алу, суүткәргеч челтәрне ремонтлау һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Девәтернә авыл җирлеге башлыгы Э.Э.Ганиев